| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**<br>**ГОРОДА БУИНСКА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БУА**<br>**ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Буа шәһәре КАРАР

10.04.2026 №18

Буа муниципаль районы Башкарма комитетының «16 яшькә җиткән балигъ булмаганнарга никахлашуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 28 июлендәге 41 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе нигезендә, Буа шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Буа муниципаль районы Буа шәһәре Башкарма комитеты карар бирә:

1. Буа муниципаль районы Башкарма комитетының «16 яшькә җиткән балигъ булмаганнарга никахлашуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 28 июлендәге 41 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Төзелгән запросны формат-логик тикшерү орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче гарызнамәнең электрон рәвешендәге һәр кырын тутырган вакытта, бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал сорауның электрон рәвешендәге дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры сорауның электрон рәвешендәге мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителә.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/, һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Буа муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://buinsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә һәм мәгълүмат стендларында рәсми рәвештә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам

Буа шәһәре Башкарма комитеты
җитәкчесе                                                  А.М.Сафин